КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 2 декабрь г.Казань № 1031

Татарстан Республикасы физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын (шул исәптән әһәмиятле халыкара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын) үткәрү чыгымнары нормаларын раслау турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктындагы «д» пунктчасы һәм «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларның туклануын тәэмин итүгә чыгымнар нормаларын;

рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларның яшәвен тәэмин итүгә чыгымнар нормаларын;

рәсми физкультура чараларына һәм спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләүгә чыгымнар нормаларын;

рәсми спорт чараларында катнашучылар өчен фармакология, торгызу чаралары, витаминлы һәм аксым-глюкозалы препаратлар, гомуми дәвалау билгеләнешендәге медикаментлар һәм бәйләү материаллары белән тәэмин итүгә чыгымнар нормаларын;

рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә бүләкләү атрибутикасын (истәлекле призларны) алуга чыгымнар нормаларын;

рәсми физкультура чараларында һәм төрле дәрәҗәдәге спорт чараларында катнашучыларны автотранспорт белән тәэмин итүгә чыгымнар нормаларын;

рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә спорт корылмаларыннан файдаланган өчен аренда түләве чыгымнарын каплауга нормалар;

электрон-техник җиһаз, контроль-үлчәү приборлары белән тәэмин итү хезмәтләре кыйммәте;

рәсми физкультура чараларына һәм спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен административ-хуҗалык һәм хезмәт күрсәтү персоналына түләүгә чыгымнар нормаларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чаралары календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәнү-күнегү чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 160 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чаралары календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәнү-күнегү чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 160 нчы карары белән расланган физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәнү-күнегү чараларын үткәргәндә спортчыларның, тренерларның һәм белгечләрнең туклануын тәэмин итүгә чыгымнар нормаларына үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 26 июль, 509 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чаралары календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәнү-күнегү чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 160 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 21 сентябрь, 868 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чаралары календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәнү-күнегү чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 160 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 26 август, 909 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының физкультура-савыктыру һәм спорт чаралары календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм өйрәнү-күнегү чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 160 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 ел, 9 апрель, 208 нче.

3. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

Рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларның туклануын тәэмин итүгә чыгымнар нормалары

| Т/с | Чаралар категориясе | Бер көнгә бер кешегә чыгымнар нормасы, сум |
|---|---|---|
| 1. | Төбәк һәм муниципальара физкультура чаралары һәм спорт чаралары | 700 гә кадәр |
| 2. | Бөтенроссия физкультура чаралары һәм спорт чаралары | 1 300 гә кадәр |
| 3. | Спортның олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия төрләре буенча халыкара спорт чаралары | 1 300 гә кадәр |
| 4. | Спортның олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия төрләре буенча халыкара спорт чаралары | 1 300 гә кадәр |

Искәрмә. Рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә катнашучыларның туклануын тәэмин итүгә нормативтан артык булган чыгымнарны каплау оешмаларның эшмәкәрлек һәм керем бирә торган башка эшчәнлегеннән алынган акча, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

_______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

Рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларның яшәвен тәэмин итүгә чыгымнар нормалары

| Т/с | Яшәү өчен торак пунктлар категорияләре исеме | Бер көнгә бер кешегә бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Мәскәү шәһәре, Санкт-Петербург шәһәре, Сочи шәһәре | 2 500 гә кадәр |
| 2. | Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре;<br>Ерак Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 2 500 гә кадәр |
| 3. | Россия Федерациясе территориясендә башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 2 000 гә кадәр |

Искәрмә. Рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларында катнашучыларның яшәвен тәэмин итүгә нормативтан артык булган чыгымнарны каплау оешмаларның эшмәкәрлек һәм керем бирә торган башка эшчәнлегеннән алынган акча, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

## Рәсми физкультура чараларына һәм спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләүгә чыгымнар нормалары

| Т/с | Судья вазыйфалары исеме | Судья категорияләрен исәпкә алып, түләүләр күләме, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ХК*, БК | 1 К | 2К | 3К/Я/С | категориясез |
| 1. | Баш судья | 1 490 | 1 096 | - | - | - |
| 2. | Баш судья-секретарь | 1 490 | 1 096 | - | - | - |
| 3. | Баш судья урынбасары, баш сәркатип | 1 100 | 918 | 733 | - | - |
| 4. | Судьялар | 998 | 796 | 679 | 624 | 530 |
| Спортның командалы уен төрләре | | | | | | |
| 5. | Уенның баш судьясы | 870 | 696 | - | - | - |
| 6. | Уенның баш судьясы ярдәмчесе | 635 | 547 | - | - | - |
| 7. | Инспектор (техник делегат, комиссар) | 679 | - | - | - | - |
| 8. | Судьялар (бригада составында) | 515 | 484 | 445 | 406 | 359 |

* Шартлы билгеләр исемлеге:

ХК – халыкара категориядәге спорт судьясы;
БК – бөтенроссия категориясендәге спорт судьясы;
1К – беренче категориядәге спорт судьясы;
2К – икенче категориядәге спорт судьясы;
3К – өченче категориядәге спорт судьясы;
Я/С – яшь спорт судьясы.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

Рәсми спорт чараларында катнашучылар өчен фармакология, торгызу чаралары, витаминлы һәм аксым-глюкозалы препаратлар, гомуми дәвалау билгеләнешендәге медикаментлар һәм бәйләү материаллары белән тәэмин итүгә чыгымнар нормалары

| Спорт чаралары исеме | Бер көнгә бер кешегә чыгымнар нормасы, сум | |
|---|---|---|
| | Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә | Татарстан Республикасында |
| 1. Бөтенроссия һәм халыкара спорт чаралары: | | |
| Россия Федерациясе җыелма командасының төп составының (әгъзаларының) җәйге һәм кышкы олимпия спорт төрләре буенча | 150 гә кадәр | 120 гә кадәр |
| Россия Федерациясе җыелма командасының резерв составының олимпия уеннарына карамаган спорт төрләре, олимпия уеннарына караган спорт төрләре һәм паралимпия һәм сурдлимпия уеннары программасына керә торган спорт төрләре буенча | 120 гә кадәр | 90 га кадәр |
| 2. Уку-күнегүләр ясау, күнегү ясау чаралары: | | |
| Россия Федерациясе җыелма командасының төп составының (әгъзаларының) җәйге һәм кышкы олимпия спорт төрләре буенча | 500 гә кадәр | 380 гә кадәр |
| Россия Федерациясе җыелма командасының резерв составының олимпиягә караган спорт төрләре, паралимпия һәм сурдлимпия уеннары программасына керә торган спорт төрләре буенча | 400 гә кадәр | 300 гә кадәр |
| спортның олимпия уеннарына карамаган төрләре, паралимпия һәм сурдлимпия уеннары программасына керми торган спорт төрләре буенча | 300 гә кадәр | 200 гә кадәр |

Искәрмә. Россия Федерациясе спорт җыелма командасының төп составын (әгъзаларын) рәсми халыкара ярышларга әзерләгәндә медикаментлар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе боерыклары буенча, спорт табиблары яисә белгечләр белән килештереп, фармакология белән тәэмин итүнең индивидуаль план-графиклары нигезендә гамәлгә ашырыла.

________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

Рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә бүләкләү атрибутикасын (истәлекле призларны) алуга чыгымнар нормалары

| Чаралар исеме | Бүләкләү атрибутикасы (истәлекле призлар) бәясе, сум | |
|---|---|---|
| | команда ярышлары | шәхси ярышлар |
| 1. Татарстан Республикасы территориясендә уздырыла торган халыкара физкультура чаралары һәм спорт чаралары: | | |
| I урын | 2 000 гә кадәр | 1 500 гә кадәр |
| II урын | 1 800 гә кадәр | 1 300 гә кадәр |
| III урын | 1 600 гә кадәр | 1 100 гә кадәр |
| 2. Төбәк һәм бөтенроссия физкультура чаралары һәм спорт чаралары: | | |
| I урын | 1 500 гә кадәр | 1 200 гә кадәр |
| II урын | 1 300 гә кадәр | 1 000 гә кадәр |
| III урын | 1 100 гә кадәр | 800 кә кадәр |

Искәрмәләр:

1. Бүләк буларак истәлекле призлар бәясенә эквивалент булган тере акча бирү тыела.

2. Спортның уен команда төрләрендә һәм команда дисциплиналарында призлы урыннар алган командалар – кубоклар белән, ә командаларда катнашучылар Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы медальләре һәм дипломнары белән бүләкләнә.

3. Татарстан Республикасы кубокларында чыгыш ясау йомгаклары буенча I урын алган катнашучыларга яки командаларга – кубок, медаль һәм диплом, ә II һәм III урыннар өчен приз алучыларга медальләр һәм дипломнар бирелә.

4. Җиңүче спортчыларның һәм приз алучыларның (командаларның) укытучы тренерлары һәм тренерлары Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы дипломнары белән бүләкләнә.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

Рәсми физкультура чараларында һәм төрле дәрәҗәдәге
спорт чараларында катнашучыларны автотранспорт белән тәэмин итүгә
чыгымнар нормалары

| Т/с | Автотранспорт төре | 1 сәгатькә аренда бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | автобус | 2 100 гә кадәр |
| 1.1. | Югары дәрәҗәдә уңайлы автобус | 2 500 гә кадәр |
| 2. | Микроавтобус (иң күбе 9 урын) | 1 200 гә кадәр |
| 2.1. | Югары дәрәҗәдә уңайлы микроавтобус (халыкара ярышлар уздырганда) | 1 400 гә кадәр |
| 3. | Җиңел автомобиль | 1 200 гә кадәр |
| 3.1. | «Люкс» классындагы җиңел автомобиль | 1 600 гә кадәр |
| 4. | Йөк күтәрүчәнлеге 3,5 тоннага кадәр йөк автотранспорты | 1 300 гә кадәр |
| 4.1. | Йөк күтәрүчәнлеге 3,5 тоннадан артык йөк автотранспорты | 1 800 гә кадәр |
| 5. | «Ашыгыч ярдәм» автомашинасы | 2 800 гә кадәр |

Искәрмәләр:

1. Спорт көймәләрен, яхталарны, атларны ташу буенча махсус автоконструкцияләр өчен түләү оешмалар белән шартнамәләр буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.
2. Автотранспорт арендасы гадәти ярышларда көненә 10 сәгатьтән һәм халыкара ярышларда көненә 12 сәгатьтән артмаска тиеш.

______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

## Рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә спорт корылмаларыннан файдаланган өчен аренда түләве чыгымнарын каплауга нормалар

| Спорт корылмасы тибы | Бер сәгатькә аренда бәясе, сум | |
|---|---|---|
| | бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чаралары | төбәк һәм муниципальара физкультура чаралары һәм спорт чаралары |
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Физкультура чаралары һәм спорт чаралары үткәрү өчен кулланыла торган спорт корылмалары: | | |
| а) ачык яссы спорт корылмалары: | | |
| уен мәйданчыклары, кырлар | 2 340 | 1 248 |
| теннис кортлары | 4 368 | 3 120 |
| стадионнар | 7 200 | 6 080 |
| тимераякта шуу өчен табигый боздан юллар | 4 800 | 3 680 |
| тимераякта шуу өчен ясалма боздан юллар | 10 000 | 8 550 |
| б) ябык спорт корылмалары: | | |
| спортның уен төрләре өчен спорт заллары | 3 124 | 1 846 |
| универсаль спорт заллары, спорт сарайлары (спортның җәйге төрләре өчен кулланыла торган), манежлар, теннис кортлары | 9 372 | 7 242 |
| боз спорт сарайлары һәм боз стадионнары, тимераякта шуу өчен ясалма боздан юллар | 13 490 | 11 786 |
| 2. Бассейннар: | | |
| 50 метрлы ябык | 11 200 | 9 600 |
| 25 метрлы ябык | 9 600 | 7 360 |
| 50 метрлы ачык | 6 300 | 4 500 |
| 25 метрлы ачык | 5 760 | 3 680 |
| 3. Спортның ату төрләре өчен спорт корылмалары (ярдәмче урыннарны кертеп): | | |
| пуля белән ату, стендка ату | 5 781 | 4 305 |
| җәядән ату | 3 444 | 2 337 |
| 4. Ат спорты өчен спорт корылмалары: | | |
| ябык ат спорты манежлары | 7 800 | 7 242 |
| ачык спорт корылмалары: | | |
| чыгыш ясау кырлары, конкур кырлары, | 5 254 | 4 544 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| манежда йөрү кырлары, стипльчез буенча йөрү<br>күнегү ясау кыры<br>аран | <br><br>2 698<br>923 | <br><br>1 846<br>426 |
| 5. Спортның ишү төрләре өчен спорт корылмалары (академик ишү, байдаркаларда һәм каноэда ишү): | | |
| ишү каналлары<br>катер арендасы буенча хезмәтләр | 3 900<br>1 736 | 2 604<br>1 302 |
| 6. Җилкәнле спорт өчен спорт корылмалары: | | |
| яхт-клублар<br>катер арендасы буенча хезмәтләр | 3 600<br>1 600 | 2 400<br>1 200 |
| 7. Спортның чаңгы төрләре өчен спорт корылмалары (ярдәмче урыннарны кертеп): | | |
| стационар чаңгы трассалары (шул исәптән старт һәм финиш йортлары, чаңгыларны әзерләү һәм саклау өчен урыннар һ.б.)<br>ратрак (кар өстеннән йөри торган машина) арендасы<br>стационар булмаган трассаларны әзерләү<br>роллер чаңгылар трассалары<br>биатлон өчен стационар трассалар (ату мәйданы һәм ярдәмче урыннарны кертеп)<br>чаңгы белән сикерү өчен трамплиннар<br>чаңгы белән тауда шуу комплекслары (фристайл, тау чаңгысы, сноуборд һәм башкалар), трасса арендасы<br>күтәртү җайланмалары (бер көнгә бер кешегә) | 5 400<br><br>940<br>3 600<br>1 170<br>5 600<br>5 600<br>5 200<br><br>700 | 4 000<br><br>900<br>2 520<br>900<br>4 160<br>3 680<br>4 000<br><br>500 |
| 8. Велоспорт өчен спорт корылмалары: | | |
| маунтинбайк өчен трассаны әзерләү | 2 800 | 1 400 |
| 9. Башка спорт корылмалары һәм эш төрләре: | | |
| ясалма ташка менү дивары<br>спорт ориентациясе буенча ярышлар уздыру урыннарын әзерләү (бер көнгә): | 4 246 | 2 895 |
| җәйге чор<br>кышкы чор | 4 200<br>6 900 | 2 475<br>6 250 |

Искәрмәләр:

1. Спорт корылмалары хезмәтләре бәясенең исәп-хисаплары Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан барлык рәсми спорт чараларына, теләсә нинди оештыру-хокук рәвешләрендәге, милек рәвешләрендәге һәм ведомствога караган корылмаларга расланган форма буенча бирелә торган техник бирем булганда тапшырылган сметалар төзүгә заявкаларны тикшерү вакытына карап тикшерелә.

2. Әлеге таблицага кертелмәгән спорт корылмалары хезмәтләренең бәясе

күрсәтелә торган хезмәтләр җентекләп таркатып язылган мәгълүматлар яки бәяләр бирү буенча исәпләп чыгарыла.

3. Ат спорты буеча ярышлар үткәрәндә бер ат арендасының бәясе бер көнгә 1 200 сум тәшкил итә.

4. Спорт корылмалары хезмәтләре өчен түләү рәсми республика һәм бөтенроссия ярышларында бер көнгә 10 сәгатьтән, ә Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган халыкара ярышларда бер көнгә 12 сәгатьтән артмаска тиеш.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

Электрон-техник җиһаз, контроль-үлчәү приборлары белән
тәэмин итү хезмәтләре кыйммәте

| Аппаратура (җиһаз) төре | Бер көнгә бәясе, сум | |
|---|---|---|
| | бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чаралары | төбәк һәм муниципальара физкультура чаралары һәм спорт чаралары |
| 1. Фотофиниш (1 комплект) | 3 970 кә кадәр | 3 000 гә кадәр |
| 2. Таймрекордер (электрон хронометр) (1 данә) | 3 970 кә кадәр | 3 000 гә кадәр |
| 3. Компьютер белән тәэмин итү (1 комплект (бастырып чыгара торган җайланма – принтерны кертеп)) | 2 300 гә кадәр | 1 800 гә кадәр |
| 4. Электрон судья-мәгълүмат аппаратурасы:<br>берьяклы<br>ике яклы | <br><br>3 000 гә кадәр<br>5 000 гә кадәр | <br><br>2 000 гә кадәр<br>4 000 гә кадәр |

Искәрмә. Әлеге таблицага кертелмәгән электрон-техник җиһаз һәм контроль-үлчәү приборлары белән тәэмин итү буенча хезмәтләр бәясе күрсәтелә торган хезмәтләр җентекләп таркатып язылган мәгълүматлар яки бәяләр бирү буенча исәпләп чыгарыла.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 2 декабрь, 1031 нче
карары белән расланды

Рәсми физкультура чараларына һәм спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен административ-хуҗалык һәм хезмәт күрсәтү персоналына түләүгә чыгымнар нормалары

| Т/с | Вазыйфалар исеме | Бер сәгатькә түләү күләме, сум |
|---|---|---|
| 1. | Җыю башлыгы (администратор) | 201 |
| 2. | Комендант | 175 |
| 3. | Дистанция һәм трассалар башлыгы | 201 |
| 4. | Дистанция һәм трассалар башлыгы урынбасары | 190 |
| 5. | Спортның җәйге төрләре буенча контролер | 175 |
| 6. | Спортның кышкы төрләре буенча контролер | 190 |
| 7. | Спорт судноларына хезмәт күрсәтү буенча эшче | 175 |
| 8. | Техник-моторист | 201 |
| 9. | Техник, моторист-коткаручы | 201 |
| 10. | Ратрак (кар өстеннән йөри торган машина) йөртүче | 175 |
| 11. | Оператор | 201 |
| 12. | Спорт чараларына хезмәт күрсәтү буенча эшче | 175 |
| 13. | Ярдәмче эшче | 175 |
| 14. | Рәссам | 210 |
| 15. | Видеотехникага хезмәт күрсәтү буенча инженер | 220 |
| 16. | Аккомпаниатор | 205 |
| 17. | Ветеринария табибы | 285 |
| 18. | Ат карауучы | 175 |
| 19. | Механик | 201 |
| 20. | Табиб | 285 |
| 21. | Шәфкать туташы | 205 |
| 22. | Күзәтү ясаучы, махсус корреспондент, матбугат сәркатибе | 220 |

_______________